Әлмәт шәһәре Башкарма комитеты

КАРАРЫ

«22» январь 2019 ел №09

Җир кишәрлегеннән һәм капиталь
төзелеш объектыннан шартлы рәвештә
файдалануга рөхсәт бирү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 39 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14, 15 статьясы,Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының 2009 елның 25 декабрендәге 366 номерлы карары белән расланган "Әлмәт шәһәре" муниципаль берәмлеге Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре белән, Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгының "Җир кишәрлекләреннән рөхсәт ителгән файдалану төрләре классификаторын раслау турында» 2015 елның 30 сентябрендәге 709 номерлы боерыгы нигезендә, Әлмәт шәһәре башлыгының «Гавами тыңлауларны билгеләү турында» 2018 елның 19 октябрендәге 19 номерлы карары нигезендә узган гавами тыңлаулар нәтиҗәләре буенча ( «Альметьевский вестник» газетасы 2018 елның 15 ноябрендәге 48 (1089) номерлы басма),

БАШКАРМА КОМИТЕТ КАРАР БИРӘ:

1. Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Әлмәт муниципаль районы, Әлмәт шәһәре, Төзүчеләр пр-кт, 62а йорты-«авторемонт остаханәләре» адресы, кадастр номеры 16:45:050114:407 булган җир кишәрлегеннән шартлы рәвештә файдалану төренә һәм капиталь төзелеш объектларына рөхсәт бирергә.

2. «Әлмәт муниципаль районы архитектура һәм шәһәр төзелеше Идарәсе» Муниципаль бюджет учреждениесенә (Мордагулова Р.Р.) әлеге карарны Татарстан Республикасы буенча «Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Федераль кадастр палатасы» федераль дәүләт бюджет учреждениесе филиалына (Мозаффарова Л. А.) җибәрергә.

3. Район башкарма комитетының хокук идарәсенә (Ханнанова Ә.Б.) әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталына (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет җитәкчесенең төзелеш буенча урынбасары Мөхәммәтҗанов А.А.ка йөкләргә.

Шәһәр  Башкарма комитеты җитәкчесе                                    Л.Ф. Валеев